СОВЕТ БУРНАШЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
БУРНАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

24.04.2020 с. Татарское Бурнашево 74-339

### Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Борнаш авыл җирлеге Советына депутатлар сайлауларын үткәрү өчен бер мандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында

"Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 7 маендагы 21-ТРЗ номерлы 26 статьясы нигезендә

Югары Ослан муниципаль районы
Борнаш авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Борнаш авыл җирлеге Советына депутатлар сайлауларын үткәрү өчен бер мандатлы сайлау округлары схемасын расларга (1 кушымта).
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә рәсми сайтында, Борнаш авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Борнаш авыл җирлеге башлыгы С. В. Бурукин

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Борнаш авыл җирлеге Советының
2020 елның 24 апрелендәге
74-339 номерлы карарга
кушымта

ОКРУГЛАР СХЕМАСЫ

| |
|---|
| 1 номерлы Татар Борнашы бермандатлы сайлау округы |
| Округка Татар Борнашы авылы, Совет ур., 1-24, 54тән 63кә кадәр йортлар керә. Сайлаучылар саны 84 кеше. |
| 2 номерлы Татар Борнашы бермандатлы сайлау округы |
| Округка Татар Борнашы авылы, Школьная, Новая, Молодежная, Луговая, Дубравная, Садовая, Зеленая урамнары керә.<br>Сайлаучылар саны 83 кеше. |
| 3 номерлы Татар Борнашы бермандатлы сайлау округы |
| Округка Татар Борнашы авылы, Совет урамы, 25тән 53кә кадәр йортлар керә. Сайлаучылар саны 83 кеше. |
| 4 номерлы Татар Борнашы бермандатлы сайлау округы |
| Округка Татар Борнашы авылы, Беренче Май урамы, 15-39 йортлар керә .<br>Сайлаучылар саны 73 кеше. |
| 5 номерлы татар Борнашы бермандатлы сайлау округы |
| Округка Татар Борнашы авылы, Беренче Май урамы, 1дән 14кә кадәр һәм 40тан 48кә кадәр йортлар керә.<br>Сайлаучылар саны 75 кеше. |
| 6 номерлы Юмат бермандатлы сайлау округы |
| Округка Татар Борнашы авылы, Октябрь урамы, Беренче Май урамы, 49, Юмат авылы керә.<br>Сайлаучылар саны 63 кеше. |
| 7 номерлы Каинки бермандатлы сайлау округы |
| Округка Каинки, Ломовка, Гаврилково, Тихий Плес авыллары керә.<br>Сайлаучылар саны 61 кеше. |